**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# О внесении изменений в качественные и количественные показатели критериев, которым должны соответствовать масштабные инвестиционные проекты, для реализации которых допускается предоставление земельных участков в аренду без проведения торгов

В целях содействия развитию территорий опережающего социально-экономического развития **постановляю:**

1. Внести в качественные и количественные показатели критериев, которым должны соответствовать масштабные инвестиционные проекты, для реализации которых допускается предоставление земельных участков в аренду без проведения торгов, установленные Указом Президента Республики Татарстан от 7 декабря 2015 года № УП-1170 «Об установлении качественных и количественных показателей критериев, которым должны соответствовать масштабные инвестиционные проекты, для реализации которых допускается предоставление земельных участков в аренду без проведения торгов», следующие изменения:

а) строку «Создание или увеличение количества рабочих мест» изложить в следующей редакции:

«

| | |
|---|---|
| Создание или увеличение количества рабочих мест | Инвестиционный проект предполагает строительство объектов, размещение которых позволит увеличить количество рабочих мест в муниципальном образовании, на территории которого они размещаются, не менее чем на 50 рабочих мест на территориях сельских и городских поселений или не менее чем на 100 рабочих мест на территориях городских округов, или не менее чем на 30 рабочих мест на территории опережающего социально-экономического развития при осуществлении ее резидентом видов экономической деятельности, определенных решением Правительства Российской Федерации о создании территории опережающего развития, в том числе на 20 рабочих мест – в течение первого года после включения юридического лица в реестр |

| | |
|---|---|
| | резидентов территории опережающего социально-экономического развития »; |

б) строку «Требование к предполагаемому объему инвестиций» изложить в следующей редакции:

| | |
|---|---|
| « Требование к предполагаемому объему инвестиций | Инвестиционный проект предполагает общий объем инвестиций более 350 миллионов рублей или объем капитальных вложений более 50 миллионов рублей на территории опережающего социально-экономического развития при осуществлении ее резидентом видов экономической деятельности, определенных решением Правительства Российской Федерации о создании территории опережающего развития, в том числе 5 миллионов рублей – в течение первого года после включения юридического лица в реестр резидентов территории опережающего социально-экономического развития ». |

2. Настоящий Указ вступает в силу со дня его подписания.

**Президент Республики Татарстан** **Р.Н. Минниханов**

АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН * ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
ГОМУМИ БҮЛЕК

Казань,Кремль
03 ноября 2016 года
№ УП-981

**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# Аларны гамәлгә ашыру өчен җир кишәрлекләрен сатуга куймыйча арендага бирү рөхсәт ителгән масштаблы инвестиция проектлары туры килергә тиешле критерийларның сыйфат һәм сан күрсәткечләренә үзгәрешләр кертү турында

Алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территорияләрен үстерүгә булышлык итү максатларында **карар бирәм:**

1. Аларны гамәлгә ашыру өчен җир кишәрлекләрен сатуга куймыйча арендага бирү рөхсәт ителгән масштаблы инвестиция проектлары туры килергә тиешле критерийларның Татарстан Республикасы Президентының «Аларны гамәлгә ашыру өчен җир кишәрлекләрен сатуга куймыйча арендага бирү рөхсәт ителгән масштаблы инвестиция проектлары туры килергә тиешле критерийларның сыйфат һәм сан күрсәткечләрен билгеләү турында» 2015 елның 7 декабрендәге ПУ-1170 номерлы Указы белән билгеләнгән сыйфат һәм сан күрсәткечләренә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) «Эш урыннары булдыру яисә аларның санын арттыру» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| « Эш урыннары булдыру яисә аларның санын арттыру | Инвестиция проекты алар урнашкан территориядәге муниципаль берәмлектә эш урыннары санын авыл һәм шәһәр җирлекләре территорияләрендә кимендә 50 эш урынына яисә шәһәр округлары территорияләрендә 100 эш урынына яисә алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территорияләрендә, аның резиденты тарафыннан Россия Федерациясе Хөкүмәтенең алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территориясе төзү турында карарында билгеләнгән икътисадый эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашырганда кимендә 30 эш урынына, шул исәптән юридик зат алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территориясе резидентлары реестрына кертелгәннән соң бер ел дәвамында – 20 эш урынына арттыру мөмкинлеге бирәчәк объектлар төзүне күздә тота »; |

б) «Кертеләчәк инвестицияләр күләменә таләпләр» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| « Кертеләчәк инвестицияләр күләменә таләпләр | Инвестиция проектында гомуми күләме 350 миллион сумнан артык булган инвестицияләр яисә алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территорияләрендә, аның резиденты тарафыннан Россия Федерациясе Хөкүмәтенең алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территориясе төзү турында карарында билгеләнгән икътисадый эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашырганда гомуми күләме 50 миллион сумнан артык булган, шул исәптән юридик зат алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территориясе резидентлары реестрына кертелгәннән соң бер ел дәвамында – 5 миллион сум капиталь кертемнәр кертү күздә тотыла ». |

2. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан,Кремль
2016 ел, 03 ноябрь
№ ПУ-981